Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

08 ноябрь 2019 ел N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Әлмәт авыл җирлегенең
Дербедень авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 22 ноябренә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең Дербедень авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Дербедень авылының вак таш юлын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын авыл клубы бинасында, түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Дербедень авылы, Совет урамы, 32а йорты.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Дербедень авылы, Совет урамы, 32а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Әлмәт
авыл җирлеге башлыгы А.А. Веретенцев